ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.01.2022 г. Заинск № 05

**«Зәй муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен раслау турында» Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 2100 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен раслау турында» Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 2100 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сишәмбе көнне Зәй муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнарны шәхси мәсьәләләр буенча кабул итү көне дип билгеләргә.

1.2. 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Почта юлламаларында булырга мөмкин шартлаткыч, агулы һәм башка куркыныч әйберләрне үз вакытында ачыклау һәм зарарсызландыру максатларында, аларны тышкы яктан карау үткәрелә. Мондый әйберләр булганда яки аларның булуына шик туган очракта, почта юлламалары белән алга таба һәр эш кичекмәстән туктатыла һәм хокук саклау органнарына хәбәр ителә»;

1.3. 2.9 пунктның икенче абзацында «(кул куйган затлар белән бер үк вакытта) өчен» сүзләреннән соң «мөрәҗәгать авторына җавапны вакытында әзерләү» сүзләрен өстәргә;

1.4. 2.13 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгатьләрне карау срогы тәмамлану булып мөрәҗәгать авторына җавапны җибәрү датасы санала»;

1.5. 4.5 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр идарәчесенә йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Ю.А. Сычева
8(85558) 7-10-27
Y.Sycheva@tatar.ru